## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘРБӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 11 09.04.2015 ел

### Шәрбән авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү һәм үткәрү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 24.03.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында», «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге Советы карары:

1. Шәрбән авыл җирлеге Советы инициативасын хупларга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2015 елның 24 маенда якшәмбе көнне 7.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2015 елда Шәрбән авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән, шулай ук Шәрбән авыл җирлеге территориясендә теркәлмәгән, әмма милекләре булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, 200 сум күләмендә үзара салым чараларын кертүгә ризамы:

Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

• торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Шәрбән авылында вак таш белән капланган юлны ремонтлау Совет урамы буенча 20,0 мең сум; Крылов урамы буенча 20,2 мең сум; Беренче Май урамы буенча 20,0 мең сум.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге территориясе чикләрендә референдум даирәсен билгеләргә.

4.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге башкарма комитетына 18 яшькә җиткән сайлаучылар исемлеген төзергә һәм Шәрбән авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә раслау өчен тапшырырга.

5.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге участок сайлау комиссияләренә гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә Шәрбән авыл җирлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.

6.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

- ТР, Аксубай муниципаль районы, Шәрбән авылы, Лермонтов урамы, 6 йорт;

Аксубай муниципаль районы
Шәрбән авыл җирлеге башлыгы — Д.А. Шәрифуллин